**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге**
**Кариле авылы торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**16 ноябрь 2025 ел** **№ 2**

2004 елның 28 нче июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Кариле авылы торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1. 90% күләмендә ташлама каралган I нче төркем инвалидларын, Бөек Ватан сугышы ветераннарын, Бөек Ватан сугышы тол хатыннарын, тыл хезмәтчәннәрен, 80 яшьтән узган өлкәннәрне, 70 яшьтән узган балалары булмаган ялгыз яшәүче өлкәннәрне, Россия Федерациясе кораллы көчләрендә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын, Россия Федерациясе кораллы көчләрендә контракт буенча хезмәт итүче гражданнарны исәпкә алмаганда, Норма авыл җирлеге Кариле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнарга 2026 нче елда үзарасалымны 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- юлларны вак таш һәм асфальт-бетон белән капланган юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү.

2) торак пункт территориясен төзекләндерү:

- Карелино авылында ял итү зонасын, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыгын булдыру һәм төзекләндерү.

3) яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту:

- "Нурминка" елгасының яр буе зоналарын чистарту.

4) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:

- транспорт чарасы ярдәмендә су җыеп алу өчен Мирная урамы, Кариле авылы инеш буенда бетоннан мәйданчык төзү.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Норма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы мунципаль берәмлекләре порталы составындагы baltasi.tatarstan.ru. Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов